РОБОТ САВА
Цифрлаштыру авыл хуҗалыгына зур үзгәрешләр алып килде
> 2

ЭЛЕКТРОНМЫ? БАСМАМЫ?
Басма матбугатның киләчәге турында уйлану
> 3

ДӘРӘҖӘЛЕ БҮЛӘК
Илһам Шакиров премиясенә гаризалар кабул итү дәвам итә
> 3

ИСӘНМЕСЕЗ! SALAM!
«ВТ» – Буада яшәүче азәрбайҗаннарда кунакта
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 138 (28911) | Чәршәмбе | 21 сентябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Яшәеш

ҖЫЛЫ!

РЕСПУБЛИКАДА ҖЫЛЫТУ СЕЗОНЫ БАШЛАНДЫ

Көз җылысы җәй түгел инде ул. Урамда 20 градустан югары булса да, фатирлар суынырга өлгерде. Шуңа күпләр җылылык бирелүен көтә. Татарстанның 37 районында йортларга җылылык бирелгән инде. Калган өйләргә дә бу атна дәвамында килеп җитәр дип көтелә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Республиканы җылылык, электр, су белән тәэмин итүче оешмалар кышка әзерме? Кайсы районда әле дә җәйге эшләр төгәлләнеп бетмәгән? Бу хакта Татарстанның төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры һәм халыкны су, электр, җылылык белән тәэмин итүче оешма вәкилләре Министрлар Кабинетында узган брифингта сөйләделәр.

– Республикада җылылык белән тәэмин итү буенча махсус штаб оештырылды. Көн саен районнар белән элемтәгә керәбез, андагы хәлләрне белешеп торабыз. Әкренләп йортлар кышка әзерләнеп бетеп килә. Республикада күпфатирлы йортларның 99 проценты җылылык бирүгә әзер. Алар әзерлек паспортлары алды, – диде министр Марат Айзатуллин. – Әзерлек дигәндә, без йорттагы капиталь төзекләндерүне дә көз уңында тотабыз. Шулай ук шәхси җылытыла торган йортлардагы төтен юлларының да тәртиптә булуы кирәк. Болар җиренә җиткереп үтәлгәндә генә җылы бирергә була.

Җылы дигәннән, ул республикада иң беренчеләрдән булып 8 сентябрьдә үк Чирмешән районында яшәүчеләрнең өйләренә килгән. Министр сүзләренчә, Татарстанда барлык социаль объектларга җылылык бирелгән. Безнең халык, җылы сөяк сындырмый, дисә дә, урамда җылы килеш, торбаларның кайнар булганына зарланучылар да бар. Урам җылытабыз, ди алар.

– Безгә җылыны теге атнада ук куштылар инде. Күршеләр салкынга зарлангач, идарәче оешма каршы килмәгән. Әле иртәрәк дип уйлыйм. Төннәрен фатирда суларга һава да юк. Өйдән генә кысып куя торган төймәсе дә юк бит аның. Бирәүләр, туңам, ди, мин инде тәрәзә ачып куям, балкон ишеге ябылмый да. Узган ел җылылык өчен аена тугызар мең сум акча түләдек. Бераз салкынайткач кына җылы бирергә ярамагандыр инде, – ди Казанның Фучик урамында яшәүче Нуретдин Сабиров.

Быелның 1 июленнән җылылык өчен бәя артты. Министр әйтүенчә, 6,7 процентка. Хәзер шунысы сөендерә: җылы өчен акчаны кышкы айларда гына түлибез. Ә менә Казанның Киров районында яшәүче Гөлчәчәк Мөхәммәтова, кышкы айларда җылысыз утырмас өчен, акча да җәл түгел, ди.

– Узган ел кыш көне өебездә өч тапкыр җылылык бетте. Сәбәбен челтәрләрдәге авария дип аңлаттылар. Җылылык беткәч, суы да салкын бит әле аның. Ни юына алмыйча, ни җылына алмыйча утырдык. Фатирны сатып, «Салават күпере»нә күчендек. Монда, ичмасам, йортлар яңа, җылылыкны кысып куеп та була, – ди ул.

Күп кенә йортларның подвалында җылылыкны көйләүче төймәләр бар. Ул, һава торышына карап, өйдәге температураны нормада тота. Ә менә шәхси җылыту казаннары булган кешеләр бөтенләй ота. Алар үзләренә кайчан кирәк, шунда җылы куша. Челтәрләргә килгәндә, алдагы саннарда без республикада аларның күбесенең эштән чыкканы, төзекләндерү кирәген язган идек. Бу очрашуда да алар хакында сүз булды. «Татэнерго» оешмасының генераль директоры урынбасары Илгизәр Гайфуллин сүзләренчә, аларга караган челтәрләр дә искергән.

– Ел саен җылылык бирү системаларын төзекләндерергә тырышабыз. Әмма быел, башка еллардан аермалы буларак, эшләр азрак башкарылды. Санкцияләр аркасында кирәкле чималларга бәя күтәрелеп, без 40 чакрым челтәрне генә алыштыра алдык, – ди ул.

«Казэнерго» оешмасының генераль директоры Рөстәм Габделхаков исә, без кышка әзер, дип белдерде. Кыш көне күңелсез хәлләр килеп чыкмасын өчен, алдан ук хәстәрен күрәләр икән. Аварияләр була калса дип тә әзерләнеп куйганнар.

«Сетевая компания» оешмасының генераль директор урынбасары Альмир Латыйпов исә эшмәкәрләрне, төзүчеләрне нинди дер эшкә тотынганда, үзләре белән киңәшләшергә чакырды.

– Җылылык, электр челтәрләренә зыян салучылар күп. Нинди дер оешма килә дә казый башлый. Үзләре дә сизмәстән, чыбыкларга зыян салалар. Күпме кеше утсыз, җылысыз кала. Халыктан мөрәҗәгать булгач, без төзекләндерергә чыгабыз. Ә бит зыян салучы шалтыратып әйтсә, вакытында күп кенә күңелсезлекләрне булдырмый да калып була. Юк, алар дәшми. Челтәргә зыян салучыларга штрафлар да каралмаган. Алар килгән зыянны гына капларга тиеш, – ди ул. – Казу эшләрен башкарганчы рөхсәт кәгазе алу кирәк. Узган сезонда челтәрләргә 109 тапкыр зыян салынды. Киләчәктә игътибарлы булсыннар иде. Әле менә без үз белдеге белән казу, төзү эшләре башкарган оешмаларны катгыйрак җәзага тарту юлларын эзлибез.

Сүз башы бит шүрәле дигәндәй, җылыны кайчан кушарга тиешләр соң? Норматив буенча, 5 көн дәвамында +8 градус торса, җылылык бирелергә тиеш. Хәер, күп районнар моны көтеп тормаган. Ә менә Питрәч районы кышка әзер түгел. Тиешле документлары да кулларында юк. Әзерлек паспортлары да тиешенчә алынып бетмәгән икән.

Референдум көне билгеле

Луганск Халык Республикасы хөкүмәте Россиягә кушылу буенча референдум үткәрүне 23–27 сентябрьгә билгеләгән. Моңа кадәр ЛНРда төбәкне Россия составына кертү буенча референдум үткәрү турында закон бертавыштан кабул ителгән. Аны төбәк башлыгы Леонид Пасечник имзалаган.

Соңрак Донецк Халык Республикасының да референдумны шул көннәргә билгеләгәне мәгълүм булды.

Мөселманнар өчен мөмкинлек

Соңгы 5 ел эчендә Татарстанда банк, кредит һәм акча саклау мәсьәләләрен шәригать кануннарына туры китереп хәл итү өчен дүрт мөмкинлек пәйда булган. Болар – «Сахих инвест»та кыйммәтле кәгазьләрнең шәригать таләпләренә туры килү-килмәвен билгеләүче мобиль кушымта, «Ак Барс» банкта күчемсез милек сатып алуга хәләл кредит («рассрочка»), «Ак Барс капитал»да хәләл инвестиция, «Мирас» финанс йортында автомобиль, төзелеш материаллары һәм зур булмаган көнкүреш техникасы сатып алуга хәләл кредит.

Моннан тыш мөселманнар өчен банк карталары чыгарыла башлаячак. Аларны «Ак Барс» банкы Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы белән берлектә эшләгән. Шәригать кануннарына туры килә торган карта гадәти банк картасына охшаган. Андагы акча процентлар өстәлмичә генә саклана, клиентларның акча исәбе аерым счетларда алып барылачак. Моннан тыш акча шәригать тыйган эшчәнлек өчен тотылмаячак.

Мөселман картасы белән уен йортларында, лотерея бизнесында, хәмер һәм тәмәке сатыла торган махсус кибетләрдә алыш-биреш ясап булмаячак. Аның белән азык-төлек кибетенә йөрү мөмкинлеге каралган. Шулай ук төнге клублар һәм барларда да карта белән түләп булмаячак. Ә кафе-рестораннарда мөмкин.

Яңа паспорт бирәләр

10 ел дәвамында гамәлдә булырга тиешле яңа үрнәктәге чит ил паспортларын рәсмиләштерүгә документлар кабат кабул ителә башлаган. Бу хакта «РИА Новости» Россия Тышкы эшләр министрлыгы мәгълүматларына таянып яза.

Гамәлдән чыкмаган паспортка ия булучыларга яңа документ бирелми. Документларны тапшыруда килеп туган техник кыенлыклар бетерелгән.

Моңа кадәр Россиядә чит ил паспортларын 10 елга бирүне вакытлыча туктатып тору турында хәбәр ителгән иде. Ә 5 елга иске үрнәктәге паспортлар бирүдә өзеклекләр булмады.

Киңәш-табыш

Акмаса да, тама

СТУДЕНТЛАРГА НИНДИ ТАШЛАМАЛАР КАРАЛГАН?

Быел ил күләмендә югары уку йортларына беренче курска миллионнан артык кеше укырга керде. Көллиятләргә – 1,2 миллион чамасы. Студент исемен йөртүчеләр дәүләттән нинди ташламаларга өмет итә ала?

Кемнәргә кагыла? Урта һөнәри һәм югары уку йортларында белем алучыларга ташламалар каралган. Әмма монда да искәрмә бар. Ташламалардан файдалану өчен студент беренче тапкыр уку йортына керергә һәм бары тик дәүләт аккредитациясе узган уку йортында белем алырга тиеш. Ә моны Рособрнадзорның рәсми сайтында ачыкларга мөмкин.

Ташламаны ничек рәсмиләштерергә? Теләсә кайсы ташламаны алганда очрый торган төп баш бәласе – аларның барлыгын ачыклау. ЕГИССО (Единая государственная информационная система социального обеспечения) дигән система аша яшәгән җирлеккә караган ярдәм чаралары турында тулы мәгълүмат алырга мөмкин.

Күпчелек ташламаларны студентка югары уку йортында ук рәсмиләштерергә мөмкинлек бирәләр. Шунда ук кирәкле документлар турында да әйтәләр. Профсоюз, деканат, кафедра – уку йортларындагы әнә шушы бүлекләр эшләвен дә онытмаска кирәк студентка. Матди һәм матди булмаган ярдәм турында шуларда эшләгән кешеләрдән дә күбрәк белүче булмас.

Өстенлекле хокук. Россиядә көллият һәм институтларга кергәндә өстенлекле хокукка ия булучыларның 13 категориясе билгеләнгән. Бу, әйтик, ятимнәр, сәламәтлеге чикле балалар, һәлак булган хәрби хезмәткәрләрнең балалары һәм башкалар. Өстенлекле хокуктан файдалану өчен, теге яки бу категория вәкиле булуны раслаучы документлар кирәк. Билгеле, укырга аның белән генә кереп булмый. Өстенлеккә ия булган абитуриент та имтихан тапшыра.

Укырга керешкәнче үк, студент түбән процент ставкасы белән белем алу өчен кредиттан файдаланырга хокуклы. Бу акчаны урта һәм югары белем алуга тотарга мөмкин. Кредит суммасы уку өчен түләү хакына бәйле. Ставка исә 3 процентны тәшкил итә. Укыганда студент процентларны гына түләргә, ә эшли башлагач, кредитның тулы суммасын ябарга хокуклы.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Владимир ЧУЛАНОВ, Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының баш инфекционисты:

Бүген күпләр коронавирусны аяк өстендә уздыра. Бу бик куркыныч. Ник дигәндә, чир катлаулы формага әверелергә мөмкин. Шуңа күрә коронавирус бернинди билгеләрсез, температурадан башка гына узган очракта да, берничә көн өйдә торып дәваланырга кирәк.

(«Известия» газетасыннан)

РОССИЯДӘ – ЭШ

«Сез эш урыныгыздан канәгатьме?» Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре Россиядә яшәүчеләрдән эшкә мөнәсәбәтләре турында белешкән. 38 проценты канәгать булуын әйткән.



Хәтәр чор

Яздан бирле Татарстан сырхауханәләренә талпан кадалуга бәйле рәвештә 8640 кеше мөрәҗәгать иткән. Бу сан узган елның шушы ук чорындагы белән чагыштырганда – 60, күпьеллык уртача күрсәткечтән 19,3 процентка артыграк. Роспотребнадзор идарәсе хәбәренә караганда, талпан кадалуның иң күп очраклары Казанда (2215), Чаллы (1440), Әлмәттә (776) теркәлгән. Апастан кала, барлык районнарда талпан кадалу очраклары бар.

Быел белгечләр кешеләрнең тәненнән «салдырып» алынган 2014 талпанга тикшерену уздырган. 646сында талпан боррелиозы табылган. Бу – тән тиресен, буыннар, йөрәк һәм нерв системасына «сугучы» хәтәр бактерия. Вакытында дәваланмаганда, инвалидлыкка да китерергә мөмкин. Тагын да куркынычрагы – баш мие ялкынсынуын барлыкка китерүче вируслы энцефалит табылмаган. Шулай ук тышкы мохиттәге 80 талпан да тикшерелгән. Боларының тугызында талпан боррелиозы булуы ачыкланган.

Роспотребнадзор идарәсе белгечләре кисәткәнчә, талпаннар май – июнь, шулай ук сентябрь – октябрь айларында бигрәк тә нык котыра. Аларны тәндә күрүгә үк табибка йөгерергә кирәк.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

«СЕБЕР КУӘТЕ» КӨЧСЕЗЛӘНӘ

Дөньякүләм чималга бәяләр төшү процессы башланды инде һәм ул Россияне кыен хәлгә куя. Газ торбасындагы краннарны ябып куеп, Европаны тезләндерү сәясәте әлегә көтелгән нәтиҗәне бирми. Көнбатышлылар газ саклагычларын 85 процентка һәм кайбер илләр хәтта 100 процентка да зәңгәр ягулык белән тутырып куйдылар инде. Кыш җылы килсә, Россия ягулыгыннан башка да язга чыгарга ниятлиләр. Немец сәясәтчеләре арасында өздереп: «Ни генә булмасын, «Төньяк агым – 2» торбасын кулланышка кертмибез, чөнки Россия – ышанычсыз партнер», – дип әйтүчеләр күренә. Евросоюз һәм Германия җитәкчелеге, газ контракты төзү өчен, Катар юлын таптый. Катарда газ бар, әмма гарәпләр европалылардан озак сроклы килешү төзүне таләп итәләр. Башта моның белән килешмәгән көнбатышлылар, ниһаять, гарәп басымына бирешергә булдылар. Россия алдында Көнбатыш базарын тулысынча һәм озак елларга югалту куркынычы туды, чөнки Европада Путиннан соң да Себер ягулыгын алмаячакларын әйткән авазлар ишетелә. 2022 ел нәтиҗәләре буенча Европага газ сату – 50 миллиард кубометрга, 2023 елга 100 миллиард кубометрга кимер дигән рәсми саннар игълан ителде инде. «Российская газета» шул хакта яза.

Монда бер нәрсәне истә тотарга кирәк: 2000 долларлык газ бәясе ул – спот базарындагы бәя. Россия торба газын андый бәядән сатмый, озак сроклы килешүләр буенча 500 доллар тирәсеннән генә озата. Югалган газ экспорты күләмен агымны Кытай базарына юнәлтеп коткарырга телиләр. Югыйсә газны ачык һавада бушка ягарга туры килә. Әмма дә ләкин бу вазгыятьтә Кытай үз өстенлеген яхшы аңлый. Мәскәү тиз арада «Себер куәте – 2» дип аталган торбаны Монголия аша уздырып, Кытайга 50 миллиард кубометр газ сатарга тели. Инде торбаны суза башларга дигән карар кабул ителде, тик Пекинда һаман да килешүгә имза куймыйлар. «Российская газета» бу хакта: «Если Восток – дело тонкое, то Китай – тонкое вдвойне», – дип яза.

Күк асты илендә яхшы беләләр: Мәскәүнең барыр урыны юк, теләсә дә, теләмәсә дә, газны чиннар куйган шартларда сатачак. Кытай белән килешә алган очракта да бу әле экспорт югалтуларын өлешчә генә каплый. Россия газын актив сатып алучы төрекләр дә Мәскәүнең оттырышлы позициядә торуын яхшы аңладылар: газга бәяне төшерүне таләп итәләр. Әнкара болай да Себер газын арзанга алып, көньяк Европага кыйммәткә сатып ята. Хәзер Россия хисабына табышын тагын да арттырырга тели.

Һиндстан Россия нефтен арзанга алып, соңгы берничә айда гына да 4 миллиард доллардан артык акча откан икән. Без шуның кадәр югалттык дигән сүз бу.

Россиядә

ҮЗӘК БАНКЛАР ИНФЛЯЦИЯГӘ КАРШЫ

Дөньякүләм бәяләр ярышы Үзәк банкларны җиңел кредитлар өләшүне туктатырга мәҗбүр итә. Бүгенге капитализмның табигате шундый: җитештерү түбәнәя башласа, күп итеп бурычка акча өләшәсең дә базарларны җанландырып җибәрәсең. Сатып алучылар күбрәк сатып ала башлый, ихтыяҗ булгач, җитештерүчеләр күбрәк җитештерә. Җитештерү арту белән, бюджетка салымнар күбрәк керә башлый, социаль өлкәгә күбрәк акча бүлеп була. Беренче карашка бик гуманлы ысул кебек инде бу. Халыкның матди тормыш дәрәҗәсе яхшыра бит. Дөресрәге, яхшырган кебек тоела, иллюзия барлыкка килә. Әмма, бердән, кредитларны түлисе бар. Икенчедән, акча басып кредит өләшү сәясәте инфляция дигән аждаһаны мәйданга чыгара. Югарырак бәягә сатып аласың да, күбрәк бурыч түлисең. Әйе, синең затлы машинаң һәм иркен фатирың булырга мөмкин, әмма син алар өчен озак еллар буе банкларга бурычлы. Җитмәсә, көндәлек куллану товарларына һәм азык-төлеккә бәяләр күтәрелеп, синең бурыч түләү мөмкинлегеңне киметә һәм юкка чыгара.

Кредит алып, җитештерүне үстергән предприятиеләр дә бервакыт үзләренең тырмага басканнарын аңлый башлыйлар. Җитештерү арткан саен, чималга бәяләр күтәрелә. Ялланып эшләүчеләр хезмәт хакларын да күтәрүне таләп итәләр: аларның да бурыч түлисе бар. Бу – кайчан да булса бер җитештерү, үзкыйммәтнең артуы сәбәпле, түшәмгә килеп терәлә дигән сүз. Без Европада да, башка континентларда да бүген шул хәлне күзәтәбез: энергия чыганакларына бәяләр чамасыз үсү аркасында, заводлар ябыла. Ә бик түбән процент белән алган булсаң да, кредитларны түләргә кирәк. Инфляция котырганда, аларны түләү бик авыр.

Үзәк банклар менә шунда котылгысыз рәвештә инфляцияне авызлыкларга кирәк дигән дилемма алдына килеп басалар. Моны кулланучыларның аппетитын тыю юлы белән генә хәл итеп була, ягъни кредит бирүне чиклисең. Мондый очракларда кулланыла торган ставка күтәрү дигән бердәнбер механизм эшкә җигелә. Зуррак процент белән кредит аласы килми инде. Ихтыяҗ кимү бәяләрне төшерә. Яисә инфляциянең күләмен булса да киметә. Төп ставканы ничә базис пунктына күтәрүгә бәйле барысы да. Аз гына күтәрсәң, инфляция темпы кими генә. Бик югары күтәрсәң, дефляция үк мәйданга чыга. Әмма бу – тагын бер тапкыр тырма өстендә сикерүгә тиң гамәл. Җитештерү кими башлый, димәк, предприятиеләр элекке кредитларын түли алмыйлар. Эшсезлек дигән афәт гадәти кулланучының да бурыч түләү мөмкинлеген юкка чыгара. Вазгыять шундый: процент ставкасын күтәрергә ярамый, әмма күтәрмичә дә булмый. Ике юл да һәлакәткә илтә. Соңгы көннәрдә барлык илләрнең дә диярлек Үзәк банклары катастрофаның икенче юлын сайладылар. АКШ ФРСы бу атнада ставка турында чираттагы карарын кабул итәчәк. Белгечләр ставка 75 базис пунктка, ягъни 0,75 процентка күтәрелер дип фаразлыйлар. Англия банкы 50 базис пунктны яуларга җыена. 2022 ел башыннан 40 илнең Үзәк банкы төп ставканы 75 база пунктка һәм аннан да югарырак күтәргән инде. Якындагы арада Индонезия, Филиппин, Норвегия, Швеция, Швейцария банклары процент ставкасын күтәрергә ниятлиләр. Төп ставка күтәрелгәндә, чималга бәяләр төшә. ОПЕК+ чикләүләренә карамастан, нефть бәясе 90 доллардан түбәнгәрәк китә башлады, газ бәясе дә 2000 доллардан түбәнгәрәк тәгәрәде.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның Иранга эшлекле сәфәре тәмамланды. Кичә ул Тәһранда иде.

Татарстан Президенты шәһәрдә урнашкан автомобиль төзелеше буенча зур заводларның берсе саналган Iran Khodro компаниясе эшчәнлеге белән танышты. Сүз уңаеннан, бу компания 1962 елдан бирле эшли. Биредә 70 меңләп кеше хезмәт куя. Заводта фәнни-тикшеренү бүлекләре дә бар. Компания җиңел автомобильләр җитештерү белән шөгыльләнә. Иранннан тыш, заводның Азәрбайҗан, Мисыр, Сүрия, Венесуэла һәм Сенегалда заводлары бар.

Татарстан Президентына җитештерү линияләрен күрсәттеләр. Заводның баш инженеры республика җитәкчесенә эш үзенчәлекләрен сөйләде, машина двигательләренең Евро-5 стандартына туры килүен ассызыклады. Үз чиратында Президент биредәге эшчәнлекнең югары дәрәҗәдә оештырылуын әйтте.

Компания җитәкчелеге белән очрашу вакытында Татарстан Президенты автомобиль төзелеше өлкәсендә республиканың сәнәгый потенциалы турында сөйләде. Әңгәмә барышында кайбер компанияләрнең Россия базарыннан китүен исәпкә алып, Ирандагы җитештерүчеләр белән хезмәттәшлекнең мөһимлеген ассызыклады.

Рөстәм Миңнеханов игътибар иткәнчә, республика автомобиль төзелеше мәсьәләләрендә Иран партнерлары өчен әзерлекле персонал һәм компонентлар җитештерү белән кызыклы була ала.

***

Нәтиҗәле булсын. Татарстан Президенты Иранның беренче вице-президенты Мөхәммәд Мохбер белән очрашты һәм эшлекле сәфәр вакытында республика делегациясен кабул иткәннәре өчен рәхмәтен әйтте.

– Иран белән хезмәттәшлекне арттыруга зур игътибар бирәбез. Безнең сәфәрне оештырган өчен зур рәхмәт. Бу проектларыбызны тормышка ашыруда нәтиҗәсен бирер дип өметләнәм, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Вице-президент исә Татарстан белән Иран арасындагы уртаклыкларга игътибар итте. «Алар хезмәттәшлекне арттыруда үз өлешен кертә. Моңа таянып, без сәүдә, сәнәгать, индустрия һәм башка өлкәләрдә җитди адымнар ясый алабыз», – дигән фикердә Мөхәммәд Мохбер.

– Сәүдә-икътисади хезмәттәшлек юнәлешендә өметләр зур. «КамАЗ», вертолет, йөк-пассажир ташучы суднолар, нефть химиясе продукциясен китерү буенча ниятләр бар. Без исә Иранннан товарлар импортына өметләнәбез, – диде бу җәһәттән Рөстәм Миңнеханов.

«МӘРХӘМӘТ» ХАТЫН-КЫЗЛАРНЫ КАЙГЫРТА

Өйдә торып эшләүче хатын-кызлар нинди проблемалар алдында калган? Аларга имин хезмәт шартларын ничек тудырырга? Гомумән, гүзәл затларның хезмәткә хокуклары ничек үтәлә? Яшел Үзән районы «Васильево» санаториенда Дәүләт Советының «Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе күчмә утырышында депутатлар шундыйрак сорауларга җавап эзләде.

«Мәрхәмәт» җитәкчесе Алсу Нәбиева, эшлекле мәҗлес рәвешендәге утырышны ачып, соңгы елларда «удаленка» режимын куллануның хезмәт законын, туташханымнарның хезмәткә хокукларын үтәүгә бәйле байтак кына проблемаларны ачып салуын билгеләп үтте.

– Статистика буенча, өйдә торып эшләүчеләр саны бер ел эчендә 159 процентка арткан. Ә хезмәткәрләрнең 23 проценты «удаленка»да калу өчен хезмәт хакын кисүгә дә риза. Шул ук вакытта гүзәл затларның күпчелеге хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендәге хокукларын белми. Шуңа күрә төрле инстанцияләргә мөрәҗәгать итүчеләр саны да күбәя, – дип билгеләп үтте ул.

Татарстанда Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкил Сәрия Сабурская хатын-кызларны эшкә алу, эштән җибәрү мәсьәләләре, эшкә урнаштыру гарантияләре, хезмәт хакы, хезмәтне саклау үзенчәлекләре турында сөйләп үтте. Аның әйтүенчә, нәкъ менә хатын-кыз булулары һәм яше сәбәпле үзләрен эшкә алмау очраклары буенча мөрәҗәгать итүчеләр дә бар икән. «Мондый мәсьәләләрне «Мәрхәмәт» берләшмәсе белән берлектә карыйбыз», – диде Сабурская.

tatarstan.ru

Бурычны халык билгели

Белгечләр тәкъдим кертә, халык тавыш бирә. Дәүләт хакимияте башкарма органнарының киләсе ел өчен максатлары һәм бурычларын булдыру эше башланып китте. Белгечләр, халык белән берлектә, Сәламәтлек саклау, Мәдәният, Мәгариф һәм фән, Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау, Спорт, Яшьләр эшләре министрлыкларының 2023 елга иң мөһим эш юнәлешләрен билгеләячәк.

Белгечләрдән министрлыкларның төп эш юнәлешләре буенча тәкъдимнәр җыю башланган. Бу эш ике атна дәвам итә. Һәр министрлык өчен белгечләрне Татарстан Иҗтимагый палатасы билгеләгән. Болар – хакимият органнарында зур эш тәҗрибәсенә һәм казанышларга ия булган кешеләр, коммерциясез оешмалар вәкилләре. Аларга гавами максатлар исемлеген җентекләп эшләргә туры киләчәк.

Алга таба белгечләр тәкъдимнәре иҗтимагый советлар тарафыннан каралып, Татарстан Дәүләт хезмәтләре порталының «Опросы жителей» сервисында онлайн тавыш бирүгә чыгарылачак. Республикада яшәүчеләр бу этапта максатлар һәм бурычлар өчен тавыш бирә һәм үз тәкъдимнәрен калдыра алачак.

Иң күп тавыш җыйган максатлар һәм бурычлар буенча тәкъдимнәрнең яртысы сайлап алыначак. Ә инде иҗтимагый советларның йомгаклау утырышларында шулар арасыннан министрлыкларның киләсе елга биш-җиде эш юнәлеше билгеләнәчәк.

Исегезгә төшерәбез: министрлыкларның өстенлекле бурычлары һәм максатларын формалаштыру һәр ел саен үткәрелә. Узган елда Татарстан Дәүләт хезмәтләре порталында тавыш бирүдә 38 мең кеше катнашкан. Министрлыкларның өстенлекле бурычлары һәм аларны үтәү турындагы хисаплар белән проект сайтында (http://publictasks.tatarstan.ru) танышырга мөмкин.

Акмаса да, тама

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Төп ташламалар. Көндезге уку бүлегендә укучылар стипендия, армия хезмәтен кичектереп тору, юл хакына ташламага (анысын һәр төбәк үзе билгели) өмет итә ала. Моннан тыш тимер юл билетларын сатып алганда 50 процентлы ташлама, авиамаршрутлар өчен 23 яшькә кадәр гражданнарга субсидияләр барлыгы билгеле.

Читтән торып укучылар исә эш урыны буенча өстәмә түләүле ял алырга хокуклы, алар шулай ук кыска эш атнасына дәгъва итә ала.

Уку йортларында, гадәти стипендиядән тыш, социаль стипендия дә бар. Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар, тулы гаиләдән булмаганнар, физик мөмкинлекләре чикле затлар, I һәм II төркем инвалидлар, радиация йогынтысына дучар булучылар һәм башкалар шушы стипендияне алып укырга хокуклы.

Көндезге уку бүлегендә укучы студентларга (әгәр алар теркәлү урыны буенча укымаса) тулай торакта яшәү өчен урын бирелә. Моңа өстәп социаль стипендия алучылар тулай торак өчен айлык түләүдән дә азат ителә. Читтән торып укучылар аттестация вакытында тулай торактагы буш урыннарны били ала.

19 яшьтән башлап студентларга бушлай медицина тикшерүе узу мөмкин. 21 яшьтән исә диспансеризациягә язылырга була. Профилактик чараны өч елга бер тапкыр узу мөһим. Күпчелек медицина хезмәтләре бушлай тәкъдим ителә.

Уку йортының медицина кабинетларында студентлар бушлай прививка ясатырга, психологик ярдәм алырга мөмкин. Профсоюз билетына ия студентларга исә санаторий, профилакторий һәм ял йортларына ташламалы юлламалар да бирәләр.

Укысыннар гына! Эшләүче студентларның шулай ук хокуклары җитәрлек. Алдарак язганча, алар өстәмә ял, кыска эш көне һәм уку урынына кадәр юл хакын компенсацияләүгә өмет итә ала. Өстенлекләр студентның уку төренә дә бәйле.

Әйтик, махсус урта белем бирү учреждениеләренең көндезге уку бүлегендәге студентларга аттестация узу өчен 10 көнлек ял бирелергә тиеш. Йомгаклау аттестациясе өчен исә – 2 ай. Бу очракта хезмәт хакы сакланмый.

Вуз студентлары 15 көн ял алырга хокуклы. Дәүләт имтиханнарын тапшырган чорда исә бер айлык ял алырга мөмкин. Бу очракларда да эштән акча түләнми.

РОБОТ САВА, РОБОТ ИСӘПЛИ

ЦИФРЛАШТЫРУ СӘЯСӘТЕ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНА ДА ЗУР ҮЗГӘРЕШЛӘР АЛЫП КИЛДЕ

Сыерларны робот сава, абзарларны автомат машина җыештыра... Якын киләчәктә республика кырларында йөртүче ярдәменнән башка гына хәрәкәт итүче тракторлар да пәйда булачак. Соңгы елларда телдән төшмәгән цифрлаштыру сәясәтенең авыл хуҗалыгы тармагына алып килгән һәм алып киләчәк үзгәрешләренең берничәсе генә әле бу.

Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары Наил Залаков сүзләре белән әйтсәк, әле юклы-барлы ун ел элек кенә алда телгә алган күренешләр әкият булып тоела иде.

– Бүген инде цифрлаштырылган терлекчелек фермалары һәр районда диярлек бар. Әйтик, Саба, Аксубай, Биектау районнарындагы кайбер фермерлык хуҗалыкларында хуҗалык эшләрен тулысынча роботлар башкара. Кеше исә терлек азыгы әзерләү, терлекләрне дәвалау, шушы роботларның төзеклеген тикшерү кебек эшләрне башкара. Биредә авыр физик хезмәт төшенчәсе дә үткәндә калып бара. Киләчәктә бу барлык җирлекләрдә гадәти күренешкә әвереләчәк, – дип сөйләде ул журналистлар белән очрашуда.

Баксаң, якын киләчәктә республика кырларында йөртүче ярдәменнән башка гына хәрәкәт итүче тракторлар да пәйда булачак икән. Наил Залаков сүзләренә караганда, Казан дәүләт аграр университеты белән берлектә ике еллап шушы проектны тормышка ашыру юнәлешендә эш алып барыла. Бүген авыл хуҗалыгы тармагының өч баганасы саналган – үсемлекчелек, терлекчелек һәм эшкәртү юнәлеше – барысы да цифрлаштырыла бара.

– Дөрес, бу юнәлештә алдынгы илләрдән калышабыз әле. Әмма телгә алып сөйләрлек күрсәткечләребез бар. Бигрәк тә безнең терлекчелек тармагы үсештә. Бүген бу өлкәдә күп кенә хезмәтләрне автоматлаштырырга ярдәм иткән программалар кулланыла. Бүген терлекчелек тармагы 36 процентка автоматлаштырылган. Бу күрсәткеч арта бар. Ник дигәндә, ел саен 20ләп сөт комплексы сафка баса. Шуңа күрә бу сан ел азагына кадәр 50 процентка җитәр дип көтәбез, – ди ул.

Бүген республикадагы 3 миллион гектар сөрү җиренең 2 миллион чамасы өлешендә дә цифрлы продуктлар кулланыла. Эшкәртү тармагы да калышмый. Дөрес, авыл хуҗалыгы тармагын автоматлаштыру, цифрлаштыру эше тагын да зуррак тизлектә үсә алыр иде. Әмма монда бар да акча мәсьәләсенә килеп терәлә. Чөнки робот хезмәте кеше хезмәтенә караганда кыйммәткәрәк төшә. Килеп туган вазгыять аркасында, ватылган очракта, аларга кирәкле детальләрне табу да баш бәласенә әверелә. Шул рәвешле авыл хуҗалыгын цифрлаштыру юнәлешендә дә импорт алмаштыру сәясәте алып барырга туры килә.

Республиканың «Мәгълүмат-исәпләү үзәге» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Нияз Хәлиуллин сүзләренә караганда, авыл хуҗалыгы тармагын цифрлаштыру программаларының да хәзер үзебезнең белгечләр тарафыннан эшләнгәненә өстенлек бирәләр.

– Программа эшләүчеләр исемлегеннән чит ил белгечләрен тулысынча алып аттык. Бүген үзебездәге 23 белгеч белән эшлибез. Аларның да үзебезнең төбәктәгеләренә өстенлек бирәбез. Компетентлыклары җитеп бетмәсә, күрше төбәкләргә, әйтик, шул ук Мәскәүдә яшәүчеләргә мөрәҗәгать итәбез, – ди ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Наил Залаков сүзләренә караганда, технологияләр үзгәрү белән авыл хуҗалыгы тармагында кадрлар әзерләү мәсьәләсенә дә игътибар бермә-бер арткан. «Аграр уку йортларындагы укыту программасына үзгәрешләр кертелде. Алар хәзер цифрлаштыру юнәлешендә дә укыталар. Хуҗалык җитәкчеләрен укыту өчен дә махсус программалар булдырылды», – ди министр урынбасары.

Сүз уңаеннан, 21–24 сентябрь көннәрендә «Казан Экспо» мәйданчыгында «Kazan Digital Week 2022» халыкара форумы узачак. Анда дөньяның 15 иленнән, шул исәптән Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Белоруссия, Казахстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Иран һәм Сербиядән катнашучылар көтелә. Биредә республика авыл хуҗалыгы тармагындагы цифрлы үзгәреш нәтиҗәләре белән якыннанрак танышырга мөмкин булачак. Аларны 17 оешма тәкъдим итәчәк, 60 спикер чыгыш ясар дип көтелә.

– Бүген төп өч юнәлештә – авыл хуҗалыгы тармагын цифрлаштыруның төбәк системасын эшләү, кадрлар әзерләү һәм агробизнесны автоматлаштыру дәрәҗәсен арттыру буенча эш алып барыла. Соңгысына өстәмә акча да бүлеп бирелде. Аның нигезендә авыл хуҗалыгында автоматлаштыру системасы һәм программасын сатып алган җитештерүчеләргә бу чыгымнарның яртысын дәүләт каплый. Форумда әнә шушы эшнең нәтиҗәләре дә тәкъдим ителәчәк, – ди Нияз Хәлиуллин.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Мин кулыма китап алам

ЭЛЕКТРОН ГАЗЕТАМЫ, БАСМА МАТБУГАТМЫ?

«Кәгазь китапмы, әллә электронмы?» – дигән сорау басма матбугат чараларына да кагыла. Газета-журналлар да бүген шушы мәсьәлә алдында тора һәм басма матбугатның киләчәге бармы, электрон мәгълүмат чаралары аны күмеп китмәсме дигәнрәк борчылу белән яши. Бер җирлексез түгел инде бу. Газета-журнал алдыручыларның саны бүген бик күпкә кимеде. Авылларда, әйтик, элек һәр йортка ким дигәндә дә дүртәр-бишәр басма килә иде. Аның берсе үз төбәгендә чыккан район газетасы, республиканың төп газетасы, балалар газетасы яки журналы, Мәскәүдә чыга торган берәр газета… Кайбер журналларга ике-өч өйгә уртак итеп тә языла торганнар иде. Кулдан-кулга йөртеп укыйлар аннары, укып бетергәч, китапханәгә бирәләр. Язылалар иде элек матбугатка.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Почтальоннар исә һәр көнне шуларны таратып чыга. Бер генә көн таратмый калсалар да, авыл кешеләре тегеләрнең тупсасын шомарта башлый: «Бүген килергә тиеш иде бит, берәр нәрсә булдымы әллә?» Укыйлар иде. Шул газетада басылган хәбәрләрнең кайберләре буенча кичләрен капка төбендә фикер алышып утыралар иде.

– Укыдыгыз микән, бүген олы газетада шундый-шундый язма чыккан иде…

– Әй-йе, бигрәк һуш китәрлек нәрсәләр бар икән дөньяда… – дип эләктереп ала икенчесе һәм иплән кенә теге язманың нечкәлекләренә кереп китәләр.

Хәзер дөнья үзгәрде. Капка төбенә чыгып утырулар да юк, газета-журнал алдыручы да сирәк, почтальоннар да көн дә йөреп тормый – эшләре оптимальләште. Ихтыяҗ да бик юк бугай: хатлар язышмыйлар, телеграмма сукмыйлар… Газета өчен генә көн саен чабата туздырып йөрмәсләр ич инде. Почта хезмәтенең шулай оптимальләшүе газеталарның яңалыклар чыганагы булуына соңгы нокта куйды. Яңалыкларны җәһәт җиткерү ягыннан басма матбугат барыбер радио, телевидение кебек көндәшләреннән калыша бит инде. Газетаны җыеп-бастырып чыгарганчы күпмедер вакыт үтә. Тарату да берничә көнгә сузылгач, яңалыклар искерә. Бүгенге тизлек заманында аларның кайберләре тарихи язма булып та тоелырга мөмкин.

Яңалыкларны хәтта телевидениегә караганда да тизрәк җиткерергә сәләтле интернет барлыкка килде. Бер генә газета да аның белән ярыша алмый. Газета-журналларның электрон вариантлары да бар, әлбәттә. Ләкин журналистиканы оптимальләштерү нәтиҗәсендә, ул тиешле югарылыкта эшли алмый. Сәбәбе гади генә – кеше җитми. Белгечләр урамда эш таба алмый йөри, ә монда кеше җитми һәм эш урыннары юк. Электрон газеталарның җәһәтлеген һәм популярлыгын тәэмин итү өчен ким дигәндә өч юнәлештә эш барырга тиеш. Беренчесе – фәкать интернет өчен яза торган журналистлар штаты. Чөнки мәгълүматларны интернет аша җиткерүнең үз нечкәлекләре бар һәм алар кәгазь матбугатка язудан күпкә аерыла. Икенчесе – СЕО (сайтны эзләгечләр аша таныту) белгечләре кирәк. Эзләгечләрнең алгоритмнары әледән-әле үзгәреп тора, шул сәбәпле кичәге алымнар бүгенгә искерә. СЕО белгече менә шул үзгәрешләрне күзәтеп, электрон газетаны шуларга ярашлы итеп үзгәртеп тору, аның популярлыгын тәэмин итү өчен кирәк. СЕО бүген үзе бер тармакка әйләнеп бара һәм аның юнәлешләрен колачлау өчен бер генә кеше җитми. СММ (социаль челтәрләрдә таныту) өлкәсендә дә шундый ук хәл. Һәр челтәрнең үз нечкәлекләре, нинди генә сәләтле белгеч булмасын, бер кеше аларның барысын да югары дәрәҗәдә алып бара алмый. Шуңа күрә, электрон вариантлар бүген тулы канлы матбугат чарасы булудан бигрәк, кәгазь газета-журналларның күләгәсе булып кына кала.

Кәгазь басмаларга җиңел түгел. Интернет һәрбер кешене матбугат чарасына әйләндерү мөмкинлеге ачты. Син, әйтик, ниндидер мөһим вакыйга уртасына эләккәнсең икән, шуны видеога яки фотога төшереп, үз аңлатмаң белән социаль челтәрләргә эләсең. Моның сиңа бер кыенлыгы юк. Шушы мөһим вакыйганы яктыртуда теләсә кайсы матбугат чарасы икенчел булып кала. Ә синең язылучыларың арта. Әнә шундый мөһим һәм кызыклы яки кызганыч вакыйгаларны махсус рәвештә эзләп йөрүче кешеләр дә барлыкка килде. Эзлиләр, табалар, интернетка куялар. Аларны «блогер» диләр. Һәркем блогер була ала. Язылучылары күп булып, куйган постлары зур кызыксыну уятса, алар әле рекламада ярыйсы гына акча да эшли. Шуңа күрә блогерлар саны газета-журналлар тиражыннан да күбрәк.

Менә шундый шартларда мәгълүматны җәһәт җиткерү матбугат чаралары өчен бик кыенлаша. Ләкин эш тизлектә генә түгел… Кызыклы язмалар укучы игътибарын җәлеп итә. Чакырып торучы баш исемнәр. Шуңа күрә, кайбер басмалар мөгез чыгаруга, буш урында вакыйга ясауга, «сары»лыкка авыша башлады. Чамасын белеп кенә, ашка тоз салгандай итеп кулланганда, анысы да кирәктер инде, бәлки. Тик шулай да, әйтик, сәхнә «йолдыз»ларының нәрсә ашавы, кем белән йоклавы, кемнән авырга калуы, никахы һәм аерылышуы ялкыта башлый. Гомумән, шәхси тормыш беркадәр серлерәк булырга тиештер инде ул. Тик кайбер очракларда халык алдына артист үзе түгел, ә аның шәхси тормышы чыга, иҗаты шуңа ияреп кенә титаклый. Пиарга сусаган мескеннәр иҗатка бөтенләй кагылышы булмаган нәрсәләр кыланып, халыкны аптыратырга, аның игътибарын яуларга маташа. Моның өчен матбугатны файдалана. Газеталар да аларның популярлыгы белән күтәрелергә омтыла. Шәп бит инде: «Фәлән Фәләнова искиткеч рецепт тәкъдим итә: чүмечтәге суга салып йомырка пешерү ысулы!!!» Сәхнә «йолдыз»ларын мисалга китерүем аларның күп кулланылуы өчен генә.

Укучылар игътибарын җәлеп итәргә теләп, матбугат блогерлар дәрәҗәсенә төшә. Күңел ачу темасында эшләгән блогерларга килешә: аларның мәгълүматына барыбер ышанып бетмиләр, алардан кызык көтәләр, шамакай шикеллерәк кабул итәләр. Газета-журналларга килешми. Бу өлкәдә алар блогерларны, сары матбугатны берничек тә уза алмый, бары тик үзләренең абруйларын гына төшерәләр.

Моның кире ягы да бар – артык җитди, рәсми булып кылану. Нинди генә кызыклы булырга, дөреслекне чагылдырырга тырышмасын, бер матбугат чарасы да үзен гамәлгә куючылар ихтыярына каршы килә алмый. Ул алтын урталыкны сайларга – аерым очракларда я дәшми калырга, я вакыйганы гамәлгә куючысы күзлегеннән яктыртырга мәҗбүр. Бу бик гафу ителмәслек күренеш түгел инде, күпләр аңлый, күпләр кичерә. Тик кайбер басмаларда хуҗасына ярар өчен кирәгеннән артык тырышу, ялагайлану, аның уңышларын күпертеп күрсәтү, уңышсызлыкларын акларга маташу кебек нәрсәләр дә очрый. Бигрәк тә төбәк газеталарына хас инде бу күренеш. Чынлап уйласаң, аның гамәлгә куючыларга да, редакциягә дә бер файдасы да юк. Халык бик надан түгел бит инде хәзер, ул әллә ничә төрле чыганактан мәгълүмат ала һәм барысының да диярлек асылын чамалап тора. Һәм гайрәте чигә, ышанычы югала.

Халыкта ташка басылган сүзгә ышану бетеп җитмәгән әле. Басма матбугат аягында нык басып торсын өчен, нәкъ менә шул ышанычны файдаланырга кирәк тә бугай. Тормышның катлаулы вакыйгаларын, кызык һәм кызганыч хәлләрен гади тел белән аңлатып бирә алган, аларны анализлый белгән мәкаләләр күпкә отышлырак шикелле. Кәгазьдә басылган язмалар хакыйкать шикелле кабул ителә, шуңа алар дөреслектән ерак китмәскә, объективлыкка омтылырга тиештер. Әлбәттә, карашлар төрле була. Ләкин укучы аларның субъектив нәрсә, шәхси мөнәсәбәт икәнен аңлый икән, бу үзе үк объектив күренешкә, фикер алышуга әйләнә. Кәгазьдә басылган сүзнең бәясе югары, язучының җаваплылыгы да зур. Кәгазь басмаларны нәкъ шушы нәрсә саклап калачак. Тирә-ягында кемнәр генә нинди кызыклы нәрсәләр сөйләсә дә, акыллырак кешенең төпле сүзенә мохтаҗлык югалмый бит инде. Монда да шундыйрак хәл.

Басма матбугат юкка чыгар дип уйламыйм. Аның үз укучысы бар һәм булачак та. Ә чынлап уйлап карасаң, интернет газета белән басма газета – икесе ике нәрсә. Алар бер-берсен тулыландырып яши ала. Шулай булып калачактыр да инде ул.

Марат КӘБИРОВ

КӘГАЗЬ КАДЕРЕ

Бүген татар басма матбугаты ни хәлдә? Аның киләчәге бармы? Цифрлаштыру елы каләмчеләрнең эшчәнлегенә ничек йогынты ясый? Әлеге сорауларны журналистларның үзләренә бирдек.

Алмаз ГЫЙМАДИЕВ, «Акчарлак» газетасының баш мөхәррире:
– Башка милли матбугат чаралары белән чагыштырганда, татар матбугатының хәлен уңай бәяләр идем мин. 20 еллар чамасы элек, татар басма матбугатының киләчәге юк, бөтен кеше интернетка күчеп бетә, дигән сүзләр йөри башлаган иде. Аллага шөкер, ул фаразларның берсе дә чынга ашмады. Бүген татар газета-журналлары яхшы гына тираж белән үз укучысына таратыла. Дөрес, басма матбугатны күбесенчә авылларда гомер итүчеләр укый. Гомумән, авыл халкының менталитеты бик үзгәрмәде бит ул, йолаларыбыз, традицияләребезне дә сала саклый. Цифрлаштыруга килгәндә, мин бу күренешкә уңай карыйм. Аның да әһәмияте зур, безгә заманнан артта калмаска кирәк. Киләчәктә ни буласын белеп булмый бит. Шулай да, минем цифрга ышанычым зур түгел. Соңгы арадагы вазгыятьне исәпкә алсаң, бигрәк тә. Тотрыксызлык әле дә саклана, халыкның электрон форматларга ышанычы да кими кебек. Ташка басылган, диләр бит әле. Мин дә мәгълүматны, беренче чиратта, кәгазьдә сакларга кирәк дип саныйм. Үзем исә барлык версияләрдән дә тигез файдаланам. Һәркайсының үз урыны. Яңалыклар, ниндидер мәгълүмати язма булса, телевидение яки газета-журналны көтеп торып булмый, интернеттан ачып карыйм. Аналитик, тирән эчтәлекле язмаларны газета-журналлардан укыйм. Телевидениене үз эшчәнлегемә кагылышлы тапшырулар белән танышу өчен кулланам.

Данил СӘФӘРОВ, «Матбугат.ру» порталының баш мөхәррире:
– Цифрлаштыру елын әллә ни сизмәдем. Казанда зур IT-парк ачылды, мөгаен, шул гына искә төшәдер. Ә тулаем алганда, 2022 ел алдагы еллардан «цифрлырак» булмагандыр. Киресенчә, нәкъ быел «цифрлаштыру» елында күп кенә социаль челтәрләр ябылды яки чикләнде. Контент җитештерүчеләр, шул исәптән татар матбугат чаралары, үзләре дә теләмәстән, зур аудиторияләрен югалттылар. Басма матбугатка килгәндә, аның тиражлары үсүгә бармас. Бүген газета-журналлар тиражыбызны арттыра алдык дип түгел, ә тиражыбызны саклап кала алдык дип сөенәләр. Хәер, бүген басма матбугат ул бер холдинг сыман. Аның кәгазе дә, сайты да, социаль челтәрләрдә аккаунтлары да, мессенджерларда каналлары да бар. Бер җирдә укымасаң, икенче җирдә укый аласыз.

Айсылу ХАФИЗОВА, «Идел» журналының баш мөхәррире:
– Цифрга күчү – табигый нәрсә. Бүген заман үзе шуны таләп итә. Ләкин мәгълүмат кәгазьдә дә сакланырга тиеш. Бар булганыбызны интернетка гына «тутырып», соңыннан коры кул белән калырга мөмкинбез. Басма матбугатның бүгенге әһәмиятен, иң беренче чиратта, шул билгели, миңа калса. Хәзерге вакытта татар матбугаты шундый системада эшли дә инде. Без булган барлык мөмкинлекләрдән дә файдаланырга тиеш. Ләкин моны нигә алай кирәк икәнен аңлап эш итү мөһим. Безнең буынга күпне күрергә туры килде инде, күп кенә экспериментлар безнең җилкәгә төште. Ничек кенә булса да, без заманга яраклаштык, иядәштек кебек.

Зилә МӨБАРӘКШИНА, «Татар-информ» хәбәрчесе:
– Бүген татар басма матбугатының хәле яхшы дип бәялим. Шәп дип бәяләр идем, ләкин газета-журналларның тиражлары 250–300 мең түгел. Әмма шул 15–20 мең тиражны тотып торган газеталарыбыз бар икән, шунысына да сөенәм. Игътибар итегез, бу күрсәткеч ничә еллар буе шул урында тора: артуына шикләнәм, әмма кимемәвенә шөкер итәм.

Безнең гаилә архивында элекке газета-журналлар сакланган. Әйтик, 1989 нчы елда чыккан «Татарстан яшьләре» газетасы бар. Аның тиражы ул вакытта 280 мең булган. Яки «Татарстан», «Казан утлары» журналларын алыйк, 1990 нчы елларда алар унышар мең чыккан. Шул журналларны кулга алып, берәмтекләп битләрен актарган саен, күңелдә горурлык хисе туа. Ә шул фотосурәтләргә, мәкаләләрнең горур, бәйсез башисемнәренә карыйсың да, күзгә яшь килә.

Татар халкы Татарстанда гына түгел, ерак төбәкләрдә дә басма матбугатны укыган, хәтта «егылып» укыган. Әлбәттә, интернет юк иде бит, диярләр. Ярый булмаган. Икенче яктан караганда, интернет булмагач, мондый бай, мәгърур басма мираска ия булыр идек микән соң? Шикләнәм.

Заманалар уза, көнкүрешкә төрле яңалыклар керә. Цифрлаштыру хәзер генә түгел, моннан 20 ел элек матбугатка үтеп керде, электрон матбугатлар да барлыкка килде. Аннан соң, булган басма матбугат акрынлап интернет киңлекләргә дә күчә башлады. Нәкъ шул шауқым тәэсирендә басма матбугатның тиражы сизелерлек дәрәҗәдә төште дә инде.

Әмма басма матбугатның уңышлы ягы – кәгазьгә басылып, тарихта калуында. Интернет эшләмәсә, ут сүнсә – электрон ресурслар да бер секундта юкка чыга дигән сүз. Уйларга куркыныч, әмма көннәрдән бер көнне интернетка кереп беткән электрон мирасыбыздан мәхрүм калмагаек. Шуның өчен басма матбугатка ышаныч күбрәк, аннан соң без текстны тотып карап укырга өйрәнгән. Һәм халыкны ул гадәттән тиз генә аерып булмас та. Ни дәрәҗәдә интернеттан уку тизрәк, яхшырак дисәләр дә, кайчак аннан да туеп куясың…

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Без шулай ук үз укучыларыбызның да фикерләрен белештек. Газетаның «ВКонтакте»дагы рәсми төркемендә уздырган сораштырулар нәтиҗәсе – түбәндә



Тукайга тиң булсын

Илһам Шакиров исемендәге республика премиясенә гаризалар кабул итү дәвам итә. Конкурсның быелгы үзенчәлекләре, таләпләре нинди? Матбугат очрашуында әнә шулар турында сөйләделәр.

Премия һәр ике ел саен республиканың татар җыр сәнгатенә зур өлеш керткән, җыр сәнгатендә югары осталыкка ирешкән башкаручыларга тапшырыла. Узган ел ул тәүге тапкыр бирелде.

Бәйгедә узган елдагыча өч номинация (ир-атлар, хатын-кызлар вокалы һәм халык җыры номинациясе), приз фонды – 600 мең сум. Быелгы конкурс турында Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Нотфуллин сөйләде.

– Премия бөек татар җырчысы Илһам Шакиров истәлегенә багышлап татар мәдәниятен саклау һәм башкару осталыгы дәрәҗәсен үстерү максатыннан оештырылды. Ул ике елга бер тапкыр Илһам Шакировның туган көнендә – 15 февральдә тапшырыла. Беренче елда утызга якын гариза килде. Быелгы конкурс август аенда старт алды. Гаризалар 15 ноябрьгә кадәр дәвам итәчәк, – диде ул.

Бәйгегә чит төбәкләрдән, чит илләрдән дә җырчылар катнашыр дип көтелә. Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Данис Шакиров әйтүенчә, республикадан читтә яшәүче милләттәшләребездән Бөтендөнья конгрессының татар оешмалары аша гаризалар кабул ителә.

– Татар дөньясы ул Татарстан белән генә чикләнми. Бу премия республикакүләм дип аталса да, аның катнашучылары саны да, географиясе дә бик колачлы. Илебезнең 70кә якын төбәгеннән катнашалар. Шулай ук, Үзбәкстан, Казахстан, Таҗикстан, Төрекмәнстан кебек илләрдән икенче ел гаризалар килә, – диде Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе.

Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе директоры Кадим Нуруллин «Татар моңы» фестиваленә Илһам Шакиров исеме бирелүен искәртте:

– Бу безнең дәрәҗәбезне тагын да күтәрә. Ник дигәндә, бүген популяр булган бик күп җырчылар «Татар моңы» аша танылган. Ә инде фестивальне Илһам Шакиров исеме белән бәйләү җаваплылыкны бермә-бер арттыра, – диде ул.

Илһам Шакиров премиясе Тукай премиясе дәрәҗәсендә булырга тиеш. Татарстанның халык артисты Салават Фәтхетдинов матбугат очрашуында әнә шундый фикер әйтте.

– Тукайның – үз, Илһам абыйның үз чоры. Бу премияне алу өчен көрәш булырга тиеш. Безгә җыелышып аның күләме турында да сөйләшергә кирәк әле. Бигрәк вакланабыз, зур кешенең исеме белән мондый бәяне йөртү оят, – диде халык җырчысы.

Салават Фәтхетдинов Илһам Шакиров исемен мәңгеләштерүдә журналистлардан да активлык сорады.

– Илһам абыйның исеме белән атап куйдык та шуның белән тукталдык. Исемне конкурслар оештырып кына мәңгеләштереп булмый, сез дә эшләргә тиеш. Көн саен булмаса да, Илһам абыйны искә төшереп торырга, язарга кирәк. Бәйгегә чит илләрдән дә киләләр дибез, алар безгә күбрәк география өчен кирәк. Читләргә өметләнеп, әллә кайдан көткәнче, Татарстанда яшәгән, татарча сөйләшкән җырчыларны табарга, аларны күтәрергә кирәк. Быел кемнәр килер, нәрсә белән шаккатырыр, татар моңы, җырының кая таба барганын шуннан күрәчәкбез инде, – диде Салават Фәтхетдинов.

Ләйсән САФИНА

Белдерү

Кадастровым инженером Ирбулатовым Маратом Рафиковичем (почтовый адрес: 420100, г. Казань, ул. 2-ая Азинская, д. 1, контактный тел.: 89600488084, электронная почта marat_327@mail.ru, № квалификационного аттестата 16-15-841), в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:221001:16, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Авиастроительный район, ул. Волгодонская, дом 7, выполняются кадастровые работы по уточнению границ земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Выставкина Анна Игоревна (почтовый адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Волгодонская, д. 7).

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться в будние дни с 10.00 до 18.00 ч. по адресу: 420100, г. Казань, ул. 2-ая Азинская, д. 1.

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ земельного участка состоится по адресу: 420100, г. Казань, ул. 2-ая Азинская, д. 1 24 октября 2022 года в 10 часов 00 минут.

Возражения по проекту межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются со дня опубликования в печатном издании в течение месяца по адресу: 420100, г. Казань, ул. 2-ая Азинская, д. 1.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границы земельного участка: 16:50:221001:1; 16:50:221001:8; 16:50:221001:17; 16:50:221001 (земли общего пользования).

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок.

Исәнмесез! Salam!

АЗӘРБАЙҖАН

Буада яшәүче азәрбайҗаннар безне әнә шулай дип, бай табын белән каршы алды. «ВТ» журналистлары киләсен белгәч, алар районгадагы азәрбайҗан диаспорасы рәисе Эльчин Достуев өенә җыелган иде. Хатын-кызлар милли ризыкларын әзерли, ирләр исә кунаклар каршы ала.

БЕЗГӘ МОНДА РӘХӘТ

Эльчин Достуевның Татарстанга күченүенә 30 ел булган инде. Армия сафларыннан кайткан егет Буага юл тота. Нигәдер Казан да түгел, Чаллы да түгел, нәкъ менә шушы районны сайлый ул. Үзеннән сорагач, күңелемә тынычлык таптым, халкы әйбәт, өстәвенә табигате дә матур, ди.

– 1989 ел иде. Ул чакта минем икетуган абыем монда яши иде инде. Ул да җылы каршы алды. Күп тә үтмәде, мин биредә мәхәббәтемне очраттым. Юк, юк, татар кызы түгел. Азәрбайҗан кызын Тәтештән эзләп таптым, – ди Эльчин. – Хатынымның әти-әнисе алар кечкенә вакытта Татарстанга күчеп кайткан булган. Безнең очрашу язмыш кушуы булгандыр инде. Озакка сузмыйча, гаилә корырга булдык. Барлык азәрбайҗан йолаларына туры китереп башта кыз сорадык, аннан нишан (безнеңчә никах. – **Г.Ш.**) белән туй үткәрдек. Бер-беребезне аңлап, 20 ел матур гына яшибез.

Шул арада аш бүлмәсеннән Эльчинның хатыны Султаниса күренә. Без киләсе булгач, ул да ял алган, 6 нчы сыйныфта укучы кызы белән улы да укырга бармаган. Султаниса Буада матурлык салоны ачкан. Бу эшендә ире ярдәм иткән. Султаниса сеңлесе белән эшли икән.

– Буа халкын бик яратабыз. Кешеләр ярдәмчел, ачык күңелле. Берсе белән дә сүзгә кергәнебез юк. Бик тату яшибез. Дусларыбыз арасында татарлар да, руслар да бар. Алар безне – үз бәйрәмнәренә, без үзебезнекенә чакырабыз, – ди Султаниса.

Без аннан Азәрбайҗандагы хатын-кыз хокуклары турында сорашабыз. Хәзер элеккеге кагыйдәләр бетеп бара икән. Султаниса сөйләвенчә, моннан 50 ел элек егеткә кызны әти-әнисе сайлап биргән. Аларны өйдән дә чыгармыйча тотканнар. Шулай да хәзер дә алар арасында искечә яшәүчеләр бар икән.

– Бездә иргә хөрмәт зур. Әгәр берәр кая барасың бар икән, һәрвакыт аның рөхсәтен сорарга кирәк. Мин гел шулай эшлим. Иремнең каршы килмәгәнен, миңа ышанганын да беләм. Әмма шулай өйрәнелгән инде. Һәрвакыт аңа шалтыратам.

Эльчин белән Султаниса өч бала үстерәләр. Олы кызлары Айсель кияүдә икән инде. Ире белән Казанда яшиләр. Юсиф белән Арзу мәктәптә укый. Аларның яшь аермасы бер генә ел. Бер-берсенә иптәш булсыннар дип, икесен дә бер сыйныфка укырга биргәннәр. Сыйныфташларын да, укытучыларын да яратып кына сөйлиләр.

– Дусларыбыз әйбәт. Безне чит итмиләр. Үзебез дә тырышып укыйбыз. Начар билгеләр алганыбыз юк. Мин төрле спорт түгәрәкләренә йөрдем. Әлегә самбода тукталдым. Күп кенә җиңүләрем бар. Киләчәктә Татарстанда яшәп калырга җыенам, – ди Юсиф.

Балалар дүрт телдә иркен сөйләшә: азәрбайҗанча, татарча, русча һәм инглизчә. Әтиләре Эльчин, туган телне саклар өчен өйдә үзебезчә генә сөйләшәбез, ди. Әнә шулай итеп читтә телне саклamakчылар. Тел дигәннән, Казанда алар өчен якшәмбе мәктәбе эшли. Теләге булган һәркем анда барып телен тагын да камилләштерә ала. Башкаладан читтә яшәүчеләр өчен исә «Халыклар дуслыгы» йортында урнашкан азәрбайҗаннарның Татарстандагы төбәк иҗтимагый оешмасы үз милләттәшләре өчен онлайн уку оештырган. Күп очракта видеоэлемтә аша дәресләр үткәрәләр икән.

«Без Татарстан халкына рәхмәтле!»

Эльчин Достуев әнә шулай ди.

– Татарстанда төрле милләт халыклары дус-тату яши. Кайчак сокланып та куям. Без монда үз туйларыбызны үткәрәбез. Кунаклар арасында кемнәр генә булмый. Аларга бик ошый. Үзебез дә бәйрәмнәрдә татар, рус җырларын кушып куябыз. Без моңа ияләштек инде. Татарстанны үз йортыбыз кебек кабул иттек, – ди ул. – Әмма кайчак проблемалар да килеп чыга. Туган җирдән читтә гореф-гадәтләрне, телне, йолаларны саклау кыен.

Үзегез уйлап карагыз: безнең буын – Азәрбайҗанда туып үсүчеләр. Ә монда туган безнең балалар телне, гореф-гадәтләрне саклый алырмы? Безне әнә шул борчый. Шуңа да аларга кечкенәдән барысын да өйрәтәбез. Ә Татарстан җитәкчелеге безгә телебезне, гореф-гадәтләрне, мәдәниятне саклар өчен мөмкинлекләр тудыра.

Буада яшәүче Рена һәм Ясин Абдысьлар, телне, гореф-гадәтләрне гаиләдә саклыйбыз, диләр. Моның өчен гел бергә җыелышып, күмәк бәйрәмнәр уздыру кирәк, ди алар.

– Татарстанга кайтканда миңа биш яшь иде. Милләттәшемә кияүгә чыгып, ике бала үстерәбез. Улыбыз мәктәптә укый, кызыбызга әле 2 ай тулмады, – ди Рена. – Безгә Татарстанда яшәү бик ошый. Әмма рәхәт булса да торган җир, сагындыра туган җир. Ничек тә булса елына бер тапкыр туганнарыбыз янына барырга җай табабыз. Әти-әниләребез дә Буада яши безнең. Туган якта да йортыбыз бар. Ул диңгез буенда урнашкан. Монда эшләп арыгач, анда ял итәбез.

Нәүрүз – безнең бәйрәм

Без Достуевлар гаиләсеннән: «Татарстанда нинди бәйрәмнәр уздырасыз?» – дип тә сораштык. Баксаң, азәрбайҗаннар өчен иң зур бәйрәм Нәүрүз икән. Бу көнне һәр гаилә милли тәм-томнар әзерләп, бер-берсен кунакка дәшә. Тагын шунысы да бар: Нәүрүз бәйрәмен алар бер ай алдан, һәр сишәмбе (аена дүрт тапкыр туры килә) үткәрә башлыйлар икән.

Беренче сишәмбе «Су чәршәмбесе» дип атала. Халык ырауларына ышансаң, бу көнне су яңара. Ул көнне кояш чыгуга суга баралар, аның белән юыналар. Кешеләр бер-берсен баллы ризыклар белән сыйлый. Ул бал, шикәр булырга мөмкин. Йола Азәрбайҗан авылларында әле дә җиренә җиткереп үткәрелә икән. Бу көнне су белән коенсаң, бар теләкләрең кабул була дигән ышану да бар. Су аша сикереп чыксаң, узган елгы гөнаһларың юыла икән.

Икенче сишәмбе «Ут чәршәмбесе» дип атала. Ул көнне бер малай учакны кабызып җибәрергә тиеш. Шул ут белән авырулар юкка чыга, гөнаһлар бетә, кеше яңадан тугандай була. Учакны су сибеп сүндермиләр. Ул үзе сүнәргә тиеш. Учак аша сикергән кешеләрнең кайгы-хәсрәтләре, борчулары көл белән бергә юкка чыга дигән ышану бар. Көлен исә йорттан читкәрәк ташлыйлар.

Өченче сишәмбе «Җил чәршәмбесе» дип йөртелә. Хуҗабикәләр йорттагы барлык әйберне урамга алып чыгып кага икән. Шулай ук бу сишәмбедә сөттә пылау пешереп ашыйлар. Өстәлдә җимешләр һәм орлыклардан әзерләнгән десертлар да булырга тиеш.

Дүртенче сишәмбе – «Җир чәршәмбесе». Сынамышларга ышансаң, бу көнне чын яз килә. Ул көнне күрәзәлек итәләр. Шуңа карап, ел буе ниләр буласын беләләр. Өйләнмәгән егет белән кияүгә бармаган кыз бу көнне тозлы күмәч – «Дузлу чорек» ашап йокларга ятарга тиеш. Төшендә аңа кем су китерә, булачак ире яки хатыны шул була. Тагын мондые да бар. Ул көнне кызлар урамга чыгып, күктә җиде йолдыз санарга тиеш. Шуннан соң берәү белән дә сөйләшмичә йокларга ята. Төшендә кемне күрә, шуңа кияүгә чыгачак, имеш.

Нәүрүз бәйрәме көнне бөтен гаилә бергә җыела. Балаларга бүләк тараталар. Бәйрәм көнне бөтен кеше яңа кием кияргә тиеш. Азәрбайҗаннарда бу бәйрәм бик күңелле уза.

– Бик көтеп алган бәйрәмебез бу. Ул көнне өстәлләребез сый-нигъмәттән сыгылып тора. Җиде төрле ризык әзерлибез. Аларның һәркайсы «с» хәрефеннән башланырга тиеш. Өстәлдә шулай үзебезнең милли татлы ризыкларыбыз да урын ала. Бу көнне бөтен туганнар, дуслар бергә күңел ачабыз, – ди Султаниса. – Нәүрүз көнне башка милләттән булган дусларыбызга да бүләкләр өләшәбез. Аларның да безнең шатлыгыбызны бүлешүен телибез.

Тәмле булсын!

ДОЛМА

Буада яшәүче азәрбайҗан гаиләләре безне өч төрле милли ризык пешереп каршы алды: пылау, кутабу һәм долма әзерләгәннәр иде. Газета укучыларга долма рецептын тәкъдим итәбез.

Азәрбайҗанда аның 381 төрен әзерлиләр икән. Аны әзерләү өчен фарш, дөге, укроп, кинза кирәк булачак. Долма тәмле булсын өчен майлы ит алыгыз. Эчлекне әзерләгәч, аны виноград яфракларына төреп пешерәсең.

4 кешелек долма пешерер өчен 1 кг фарш, 60–70 данә виноград яфрагы, 2 суган, 3 аш кашыгы дөге, яшел тәмләткечләр, 5 аш кашыгы атланмай, 1 чәй кашыгы тоз, ярты чәй кашыгы борыч, ярты стакан су кирәк. Долманы табынга чыгаргач, аны катыкка сарымсак уып салынган тәмләткеч белән бирәләр.

Сүзлек

- ✓ Хәерле иртә – **Sabahınız xeyir**
- ✓ Хәерле кич – **Axşamınız xeyir**
- ✓ Мәхәббәт – **Sevgi**
- ✓ Әни – **Arvadini pusmaq**
- ✓ Әти – **Dədə**
- ✓ Рәхмәт – **Təşəkkür**
- ✓ Сау бул – **Əlvida**
- ✓ Туган тел – **Ana dili**

Йолалар

Кыз сорау

Кыз сорауда чәй төп әйбер булып тора. Аларда, кызыгызны безгә бирегез, дип әйтү юк. Йортка димче киләсе алдан шыпырт кына хәбәр ителә. Ул килгәч, аңа чәй бирәләр. Әгәр аңа шикәр салганнар икән, димәк, туйга әзерләнә башларга була. Әгәр инде шикәрне чәй янына аерым чыгаралар икән, кызны бирмиләр.

Туй

Азәрбайҗаннарда туйлар бик зурлап уздырыла. Башта егет ягыннан килеп кызның кулын сорыйлар. Шунда егет ягы кызга тәм-томнар, киемнәр, алтын, хушбуй, бизәнү әйберләре салынган 15ләп кәрҗин алып килә. Ул хонча дип атала. Кыз ярәшү бәйрәме бик матур үткәрелә. Кода-кодагыйлар килешкәч, яшьләргә нишан укыйлар. Егет ягы кыз туганнарына бүләкләр алып килә. Никахтан соң туйга әзерлек башлана. Кайдадыр кыз ягы туйны аерым, егет ягы аерым ясый. Никах укытканнан соң, кыз әле әти-әнисе өендә кала. Әгәр кыз ягы туйны алдан үткәрә икән, анда егет ягы да кунакка килә. Әмма әле кызны алып китмиләр. Егет ягы туй үткәргәч кенә кызны алып китәләр. Әгәр туйны бергә үткәрсәләр, кыз егет өенә кайтып китә. Аннары бер-берсен кунакка чакыра башлыйлар.

Туйда егет ягы фатир яки йорт бүләк итә. Кыз исә шул йортка кирәкле бар нәрсәне алып бара. Кашык-тәлинкәдән башлап, караватм, телевизор, суыткычларга кадәр кайгырта. Уларына фатир бүләк итә алмаучы гаиләләр дә бар. Андыйлар яшьләрнең торак арендалап торуы өчен түли икән. Туйга 10 мең сумнан да ким акча салмыйлар. Монда кунак күп килә. Әгәр кеше килми икән, бу хуҗаны хөрмәт итмәү билгесе булып санала.

«Хна яхты» бәйрәме

Кыз кияүгә чыгар алдыннан бер атна кала бөтен туганнарын, дусларын җыеп, хна бәйрәме ясый. Кызлар уч төпләрен хнага буяп куя. Аннары кәләш кызларга үзенә бүләк ителгән кәрҗиннәрне күрсәтә. Алар бергә күңел ачалар. Аннары кәләш кияүдә булмаган кызларның башларыннан ярәшкән йөзек белән йөртә. Бу калганнар да тизрәк кияүгә чыксын өчен эшләнә.

Хөрмәт

Монда өлкәннәргә ихтирам зур. Әгәр йортка берәр олы кеше керә икән, утырып торучылар аягүрә басып каршы ала. Гаиләдә балаларны өлкәннәрне хөрмәт итәргә өйрәтеп үстерәләр. Аларда табын янына олы кеше утырмыйча, балалар якын да килми. Азәрбайҗаннар килгән кунакны бик зур бәйрәм ясап каршы ала, аны матур итеп озатып кала. Әгәр чакырып кунагың килмәсә, ул сине хөрмәт итми дигәнне аңлата.

Дин

Азәрбайҗаннар ислам динендә. Намаз укучылар да, укымаучылар да бар. Берәүне дә мәҗбүриләмиләр. Хатын-кызлар намазда булса гына яулык яба икән. Аларда хатын-кызга зиратка керү бөтенләй тыела. Кеше үлә икән, аны өйләгә кадәр җирлиләр. Аларда кешене соңгы юлга озатырга килүчеләр бик күп була. Үлгән кешенең кырыгына кадәр һәр пәнҗешәмбе бергә җыелышып, аңа багышлап дога кылалар.

ДИНИ БӘЙРӘМНӘРЕ
- *Рамазан*
- *Корбан*

МИЛЛИ БӘЙРӘМНӘРЕ
- *21 декабрь – Челлә*
- *21 март – Нәүрүз*

САН

Татарстанда 9527 азәрбайҗан кешесе яши. Шуның 100дән артыгы Буа районында гомер итә.

Сәхифәне Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде.
Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ фотолары.

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6708 данә
Гомуми тираж – 15890 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 338

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+